ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 пунктның беренче абзацында “каралган очрактан тыш,” сүзләрен “каралган очраклардан тыш,” сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15. Вәкаләтле җирле үзидарә органы әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирелүдә мәнфәгатьле гражданнарны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракта кабул итә:

1) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге гражданнар милкенә әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пункты нигезендә бушлай бирелсә;

2) гражданнар әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә түбәндәге сәбәпләр аркасында туры килмәсә:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы бетү;

б) Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китү;

в) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү, уллыкка алу кире кайтарылу, опека яисә попечительлек туктатылу;

г) ата-ананың берсенең (ата-ананың) законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында баланың (балаларның) вафат булуы;

3) гражданнар тарафыннан аларны исемлекләрдән төшереп калдыру турында гаризалар бирелсә;

4) җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында гражданнар җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса йә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калса;

5) гражданнарны исемлекләргә кертү өчен нигез булган документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килмәгән һәм гражданнарның әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен дәлилли торган белешмәләрнең булуы ачыкланса.

Гражданнарны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында хәбәр итү, вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле карар кабул иткән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат җибәреп йә аларга хәбәрнамәне имза алып тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.”;

3) 19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Гражданнарга аларга җир кишәрлеген тапшырудан баш тарту турында хәбәр итү, вәкаләтле җирле үзидарә органы тиешле карар кабул иткән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат җибәреп йә аларга хәбәрнамәне имза алып тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 72-ТРЗ